КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 октябрь г.Казань № 949

Муниципаль-шәхси партнерлык проектларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт-шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 2 өлешенең 2 һәм 8 пунктларын, 18 статьясындагы 3 өлешен гамәлгә ашыру, шулай ук муниципаль-хосусый партнерлык проектларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара нәтиҗәле һәм килешенеп хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Муниципаль-шәхси партнерлык проектларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы белән хезмәттәшлек иткәндә регламентны кулланырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин